**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе турында» 2015 елның 9 маендагы ПУ-431 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 28 июнендәге ПУ-553 номерлы, 2019 елның 13 апрелендәге ПУ-219 номерлы һәм 2020 елның 2 октябрендәге ПУ-648 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) комиссия составыннан А.Ә. Кәримовны, Н.Н. Хәбиповны чыгарырга;

б) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Галиев Илнур Наил улын – Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесен;

аны комиссия аппараты җитәкчесе итеп раслап, Коробченко Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 28 июль
№ ПУ-510